РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

3 март, 2026 ел № 17

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм куллану тәртибен раслау турында» 2022 елның 20 декабрендәге 63 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү турында

«Элемтә турында» Федераль законның 6 статьясына һәм «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актын федераль законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм куллану тәртибен раслау турында» 2022 елның 20 декабрендәге 63 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты карарына (алга таба – 63 номерлы Карар) (2025 елның 16 июнендәге 56 номерлы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 63 номерлы Карар белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирле

әһәмияттәге автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм куллану тәртибендә (алга таба – Тәртип):

**а) 2.4 нче пунктта:**

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2.4.7. 2025 елның 23 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә автомобиль юлы хуҗасы белән килештерүне таләп итми торган элемтә объектларын да кертеп, элемтә линияләрен төзү, реконструкцияләү һәм эксплуатацияләү эшләрен башкару, мондый эшләр автомобиль юлын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту белән бәйле очраклардан тыш.»;

**а) 2.4 нче пунктта:**

икенче җөмләдә «башка муниципаль хокукый актлар белән;» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле текст өстәргә:

«Федераль законда каралган очракларда, шул исәптән әлеге Тәртипнең 2.4.7 пунктчасында күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашырганда килештерү таләп ителми.»

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Андреев В.Н.